**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**НОРЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«27» февраль 2020 ел №212

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советының 2017 елның 19 июлендәге 101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлегенә үзгәрешләр кертү турында.

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматка үтемлелекне тәэмин итү хакында" 09.02.2009 елдагы 8-ФЗ номерлы федераль законы», 09.04.2015 елдагы 21-ТРЗ-номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында "Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакьнда" ТР Законы», Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Норлат авыл җирлеге Советы карар итте:

1.1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советының 2017 елның 19 июлендәге 101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат» дип аталган IV бүлегендәге 26 пункты төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны дәүләт теркәлүе узганнан соң «Зеленодольская правда» газетасында бастырырга һәм шулай ук, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокук мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодол муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның контрольдә тотуны Норлат авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Норлат авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Р.Р.Багаутдинов**